**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23нче йорт Лаеш
ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2022елның 14 октябре** **2468номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Сәйдәшев урамы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары 16:24:170149:6; 16:24:170150:2; 16:24:000000:25 булган җир кишәрлекләре территорияләрен ызанлау проектын әзерләү турында.**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Сәйдәшев урамы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары 16:24:170149:6; 16:24:170150:2; 16:24:000000:25 булган җир кишәрлекләре территорияләрен ызанлау проектын әзерләүгә карешергә.

2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2023 елның апреленә кадәр билгеләргә.

4. Физик һәм юридик затларга әлеге карар бастырылганнан соң ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне азанлау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәр җибәрергә тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

.

**Җитәкче** **А.А. Новиков**